Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге

КАРАР

2024 елның 30 январе, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында гражданнар Җыенының 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы мәсьәлә буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмра авыл җирлегендәге Зур Кукмара авылында халык җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы" гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:

«РИЗА» «КАРШЫ»

1 пунктның икенче абзацында "1000 сум" сүзен “1500 сум” сүзләре белән алыштырырга.:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия булучылар 1722 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 885 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 873 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 12 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Зур Кукмара авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-гамәлдә, дип танырга.

2.«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Зур Кукмара авылында халык җыены нәтиҗәләре турында " 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә риза буласызмы?:

««РИЗА» «КАРШЫ»

« 1 пунктның икенче абзацында "1000 сум" сүзен “1500 сум” сүзләре белән алыштырырга.»

- кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев